Республика Татарстан

Глава Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.10.19 ел Менделеевск ш. № 60

Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Менделеевск муниципаль районында яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр чорга Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше Стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында» район Советы карары проекты турында фикер алышуда катнашу өчен Менделеевск муниципаль районы», Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «муниципаль берәмлеге Уставына таянып»

КАРАР ИТӘМ:

1.«2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында»гы район Советы карары проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышуын үткәрергә.

2. Әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырырга.

3. Билгеләргә:

3.1 үткәрү урыны - ТР, Менделеевск районы, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 нче йорт, Зур зал;

3.2 үткәрү датасы һәм вакыты - 09 сәгать 00 минут, 05.10.2019.

3.3 Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, җәмәгать фикер алышуларында катнашу хокукы белән гаризалар бирелә торган адрес: Менделеевск ш., Фомин ур., 19 йорт, 3 кат, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм итү бүлеге, т. 8(855 49) 2-79-49 (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр).

3.4 Чыгыш ясау хокукы белән иҗтимагый фикер алышуларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 04.10.2019 кадәр.

4. Район Советының оештыру бүлегенә «Менделеевск муниципаль районының 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында» район Советы карары проекты буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге Карарда билгеләнгән сроклар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. Менделеевск муниципаль районының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге чорга Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше Стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында»гы район Советы Карары проектын

Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Район башлыгы вазыйфаларын
башкаручы Галеева Л.К.

Килештерелде:

юридик бүлек башлыгы Царева Е.С.

Менделеевск муниципаль районы Советы Карары проекты

2016-2021 елларга һәм
2030 елга кадәрге чорга
Менделеевск муниципаль районының
социаль-икътисадый үсеше Стратегиясенә
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40 нчы номерлы Татарстан Республикасы Законы концепциясе нигезендә, №31-ТРЗ от 5 Апрель, 2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»гы Законнар буенча Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ

1. 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә үзгәрешләр кертүне Кушымта нигезендә үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru уранаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район Советы Рәисе Чершинцев В.С.